ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«01» октябрь 2021 ел** **№ 827**

**2021 елда Арча шәһәренең Тынычлык урамы буенда 1 нче номерлы күпфатирлы торак йортында капиталь ремонтлауның проект-смета документларын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 15 өлеше нигезендә, "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган "2020-2022 елларда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы планын раслау турында" 2019 елның 27 декабрендәге 1220 номерлы карарын, смета бәяләрен билгеләү дөреслеген тикшерү буенча "Татарстан Республикасы Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы идарәсе" дәүләт автоном учреждениесенең уңай бәяләмәләрен исәпкә алып, Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елда Арча шәһәренең Тынычлык урамы буенда 1 нче номерлы күпфатирлы торак йортында капиталь ремонт буенча проект-смета документларын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.Р. Фазыловка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
"07" октябрь ел, №827
карарына кушымта

2021 елда Арча шәһәренең Тынычлык урамы буенда 1 нче номерлы күпфатирлы торак йортында капиталь ремонт буенча проект-смета документларын раслау турында мәгълүмәт

| № | Адресы | Төзелешнең гомуми смета бәясе 2021елның 2 кварталындагы бәяләрдә | Төп техник-икътисади күрсәткечләр | Раслана торган проект документларының составы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Арча шәһ., Тынычлык ур., 1 й. | 3836,23 мең сум | S=795,6 м2<br>Vстр=4008 м3<br>Катлар саны - 3<br>Төзелеш елы - 2005 | Эш сызымнары һәм түбәндәге эш төрләре буенча бүлекләр:<br>1. Архитектура чишелешләре.<br>1.1 Фасадны ремонтлау.<br>1.2 Подъездларны ремонтлау.<br>1.3 Түбәне ремонтлау.<br>2. Инженерлык җиһазлары, инженер-техник тәэмин итү челтәрләре турында белешмәләр, инженер-техник чаралар исемлеге, технологик чишелешләрнең эчтәлеге.<br>2.1 Электр системасы.<br>3. Агымдагы бәяләрдә смета документациясе. |